| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2023 Багай ав. № 2

«Җирле салымнар буенча недоимканы, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр турында» 2022 елның 30 ноябрендәге 15 номерлы Багай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Җирле салымнар буенча недоимканы, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр турында» 2022 елның 30 ноябрендәге 15 номерлы Багай авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында».

1.2. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- 6 ай эчендә мираска хокукны белдермәгән очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларга карата, вафат булган көннән алып;
- һәр төр салымнар буенча иск вакыты чыкканнан соң өч ел вакыт узу белән бәйле рәвештә;
- башкарма җитештерү тәмамлануга һәм башкарма документны түләтүчегә «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча, башкарма документны кабат бирү процедурасын үтәгәннән соң, законнарда билгеләнгән срок чикләрендә үтәүгә карата;
- 2022 елның 01 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча;
- бурычлының түләтү кире кайтарылырга мөмкин булган мөлкәте булмаганда, Россия Федерациясеннән киткән физик затларның 3 елдан артык бурычын түләү буенча бурычлары булганда;

- суд тәртибендә хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган физик затлар;
- картлар (ветераннар) йортларында яшәүче физик затлар;
- аларның статусы законнар нигезендә расланган очракта, аз керемле гражданнар;
- суд карары нигезендә һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган физик затлар.».

2. Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советының 2013 елның 23 апреленендәге 13 номерлы «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында» карарын юкка чыгарырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Багай авыл җирлеге Башлыгы — Р.Ф Кузнецова

КАЙБИЦКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
Совет Багаевского сельского поселения
Багай авыл җирлеге Советы
ИНН 1621000333